КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 октябрь г.Казань № 934

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы генераль директорын конкурс нигезендә билгеләп кую тәртибен раслау турында» 2014 ел, 13 декабрь, 984 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы генераль директорын конкурс нигезендә билгеләп кую тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы генераль директорын конкурс нигезендә билгеләп кую тәртибен раслау турында» 2014 ел, 13 декабрь, 984 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 14 сентябрь, 642 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы генераль директорын конкурс нигезендә билгеләп кую тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелеш», һәм (яки) «Юриспруденция», һәм (яки) «Икътисад» белгечлеге буенча югары белеме һәм квалификациясе булган;

төзелеш өлкәсендә һәм (яки) торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә кимендә җиде ел, шул исәптән җитәкче вазыйфасында кимендә өч ел эш тәҗрибәсе булган;»;

3.3 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шәхси (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документның күчермәсе;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин